**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 19 декабрендәге 5239 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 26 декабрендәге 4608 номерлы «Торак урыннарны Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең махсуслаштырылган торак фонды составына кертү һәм составыннан чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 26 декабрендәге 4608 номерлы «Торак урыннарны Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең махсуслаштырылган торак фонды составына кертү һәм составыннан чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 26 декабрендәге 4608 номерлы карары белән расланган Торак урыннарны Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең махсуслаштырылган торак фонды составына кертү һәм составыннан чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.3.2 пунктында, 2.5.1.1, 2.5.1.2 пунктчаларында, 2.5.2, 2.5.3, 2.7.1, 2.15.2 пунктларында, 2.16.1 пунктында 2), 6) пунктчаларында, 2.16.2, 2.16.3, 2.16.4, 3.2.3, 3.3.2, 3.6.3.2, 3.7.1 пунктларында «Республика порталы» сүзләрен, тиешле килештә куеп, «Бердәм портал, Республика порталы» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 3.3.3 пунктының сигезенче абзацыннан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу турындагы карар проекты муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан килештерелә»;

1.3. регламентның 4, 5 номерлы кушымталарында «□Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетка;» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«□Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталындагы шәхси кабинетка».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**